**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.03.2025 Казан шәһәре № 110

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2023 елның 31 августыннан 405 номерлы боерыгы белән расланган Каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2024 елның 8 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 172-ФЗ номерлы федераль законның 2 һәм 5 маддәләренә үзгәрешләр кертү турында» федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февраленнән «Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 175 номерлы карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә

**б о е р а м :**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2023 елның 31 августыннан 405 номерлы боерыгы белән расланган Каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2.1 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.1. Гариза бирүчеләр булып түбәндәгеләр була ала: физик затлар – балигъ булган гражданнар, балигъ булмаган гражданнарның законлы вәкилләре, ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән эш итүче 14 яшькә җиткән балигъ булмаганнар.»;

2.6.1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктчаны өстәргә:

«7) вәкилнең гариза бирүче исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документ (гариза вәкил тарафыннан бирелгән очракта)»;

3.3.2 пунктының уникенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлектәге 3.6.3 пунктын өстәргә:

«3.6.3. Гаризада гариза бирүче булмаган балигъ булмаган затның законлы вәкиле тарафыннан балигъ булмаганга карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең кәгазьдә тутырылган нәтиҗәсен алу турында белешмә күрсәтелгән очракта дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе, аның шәхесен раслаучы документ күрсәткәндә, күрсәтелгән затка бирелә.

Балигъ булмаганга карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең кәгазьдә язылган документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәсе, әгәр мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризада дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен шәхсән үзе алу турында күрсәткән булса, балигъ булмаганның башка законлы вәкиленә бирелми.»;

Каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министр урынбасары А.Ә.Хөсәеновка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Учреждение җитәкчесенә

________________________________________

(җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

________________________________________

________________________________________

(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)[1]

Гариза бирүченең яшәү урыны адресы һәм (яки) тору урыны адресы:

________________________________________

________________________________________

Гариза бирүченең телефоны:

_________________________

Гариза бирүченең электрон почта адресы:

________________________________________

Гариза

Миңа/ (минем балама) шәһәр читендәге ял лагерена юллама бирүегезне үтенәм.

________________________________________________________________________.

(гариза бирүченең/гариза бирүченең законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) тулысынча)

Гариза бирүченең / гариза бирүченең законлы вәкиленең туу датасы ____________________.

(туган көне, ае, елы)

Гариза бирүченең / гариза бирүченең законлы вәкиленең туу урыны____________________

________________________________________________________________________

Гариза бирүченең / гариза бирүченең законлы вәкиленең яшәү урыны адресы һәм (яки) тору урыны адресы________________________________________________________.

Баланың әти-әниләренең (законлы вәкилләренең) фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре (булганда):

әнисе/ опекуны ______________________________________________________,

(кирәклесенең астына сызарга)

әтисе/опекуны______________________________________________________

(кирәклесенең астына сызарга)

Беренче чиратта кабул итү хокукым бар ______________________________________.

(беренче чиратта кабул итүнең нигезе күрсәтелә (булган очракта)

Баланың / шөгыльләнүченең җайлаштырылган спорт программасы буенча физкультура-савыктыру әзерлегенә һәм (яки) индивидуаль тернәкләндерү программасы нигезендә чикләнгән мөмкинлекләре белән (булган очракта) яки инвалидның (инвалид баланың) тренировка дәресләрен оештыру өчен махсус шартлар тудыруга ихтыяҗы[2] бар __________________________________.

(әйе / юк)

[1] Гариза бирүче – физик затлар – балигъ булган гражданнар, балигъ булмаган гражданнарның законлы вәкилләре, шулай ук ата-аналарның (законлы вәкилләрнең)ризалыгы белән эш итүче 14 яшькә җиткән балигъ булмаганнар

[2] Әлеге абзацта, булган сәбәпләргә нигезләнеп, кирәклесенең астына сызарга.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен кәгазьдә бирергә:
- шәхсән
- гариза бирүче булмаган башка законлы вәкилгә ______________________________
(ФИАи, шәхесне раслаучы документ турында белешмәләр)

Эшчәнлекне оештыруны һәм гамәлгә ашыруны, шөгыльләнүченең хокукларын һәм бурычларын җайга салучы Оешма уставы белән таныштым

______________ ______________
(дата) (имза)

Җайлаштырылган спорт программасы буенча дәресләргә (кирәк булган очракта җайлаштырылган спорт программасы буенча дәресләр) бала / мин риза.

______________ ______________
(дата) (имза)

Рәсми интернет-каналларда һәм порталларда, шул исәптән Учреждение сайтында бала /минем турында мәгълүмат (фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта), фото-һәм видеоматериаллар) урнаштыруга риза .

______________
(дата) (имза)

Ата-аналар (законлы вәкилләр) ризалыгы белән эш итүче 14 яше тулган балигъ булмаган зат тарафыннан гариза бирүгә риза.[4]

______________ ______________
(дата) (имза)

Бала/керүче затка карата өстәмә мәгълүматлар:
медицина полисы № ______________________ бирелгән __________ ел
дәүләт пенсия иминиятләштерү иминият таныклыгы № ______________.
Ата-аналар турында өстәмә мәгълүматлар:
әнисе / опекуны ______________________________________
______________________________________________________,
(эш урыны, вазифасы, эш тел., челтәрле тел.)
әтисе / опекуны ______________________________________
______________________________________________________.
(эш урыны, вазифасы, эш тел., челтәрле тел.)

______________ ______________
(дата) (имза)